РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.08.2017 №933-п_

Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү исемлеген һәм тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы нигезендәТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, З.Йосыпов ур., 47 йорт адресы буенча урнашкан Район китапханәсе бинасы каршындагы мәйданны Саба муниципаль районы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус билгеләнгән урын буларак билгеләргә.
2. Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бүлмәләр исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).
3. Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.М. Гасимов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 августындагы 933-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар исемлеге**

| № т/б | Объект атамасы | Йортның адресы |
|---|---|---|
| 1. | Администрация бинасы | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров ур., 52 й.б., 305 каб - кече зал. |
| 2. | Администрация бинасы | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров ур., 52 й.б., 125 каб - актовый зал. |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 14
августындагы 933-п номерлы карары
белән РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен билгеләнгән биналар бирү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Муниципаль милектәге биналар түләүсез нигездә бирелә.
2. Сайлаучылар белән очрашулар өчен урыннар бирү өчен Саба муниципаль районы Советы депутаты, аның ышанычлы заты Саба муниципаль районы Башкарма комитетына бина бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.
3. Гаризада чараны үткәрүнең фаразланган датасы, аның башлануы, дәвамлылыгы, катнашучыларның якынча саны, чараны уздыру өчен җаваплы булган гариза бирү датасы, аның контактлы телефоны күрсәтелә. Гариза әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта формасы буенча рәсмиләштерелә
4. Саба муниципаль районы Советы депутатларының, аларның ышанычлы затларының очрашуларын уздыру өчен муниципаль милектәге бина бүлеп бирүгә заявка сайлаучылар белән очрашу уздырганчы 7 эш көне алдан җибәрелә һәм 3 эш көне дәвамында карала. Карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә язмача җавап бирелә.
5. Бина эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 3 сәгатьтән дә артык булмаган вакытта бирелә.
6. Урын бирүдән баш тарту өчен соратыла торган бинада башка планлаштырылган чара уздыру нигез була.
7. Урыннарның куркынычсызлыгын тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Саба муниципаль районы Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуы өчен билгеләнгән биналар бирү тәртибенә 1 нче кушымта

**Бүлмәне бирүгә**

**гариза**

Гамәлдәге кануннар нигезендә бинаны түбәндәге адрес буенча бирүегезне сорыйм: ______________________________________________________________

(җыелышны уздыру урынын күрсәтергә)

сайлаучылар белән очрашу уздыру өчен ______________________ рәвешендә, аны үткәру планлаштырыла______________________________________________________________

(җыелышны үткәрүнең фаразланган датасын күрсәтергә)

______________________________________________________________сәгатьтә,

(җыелыш үткәрелә башлау вакытын күрсәтергә)

______________________________________________________________дәвамында,

(җыелышның озынлыгын, 3 сәгатьтән артык булмавын күрсәтергә)

Катнашучыларның якынча саны: ____________________,

Чара өчен җаваплы: ________________________________________________________

(Ф.И.О атамасы, статусы)

Аның контакт номеры____________________________________,

Гариза бирү датасы: ________________________________________

Депутатның, аның ышанычлы затының имзасы ____________